# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы**
**Дәүләт Киңәшчесе турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 12 мартында
кабул ителде

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең статусын, аны вазыйфасына билгеләп кую һәм вазыйфасыннан азат итү тәртибен, аның компетенциясен, эшчәнлеген оештыру рәвешләрен һәм шартларын билгели.

1 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең статусы**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасы, вәкаләтләрен үтәвен туктаткан Татарстан Республикасы Президентының тәҗрибәсеннән һәм белеменнән Татарстан Республикасының сәяси, социаль-икътисадый һәм башка төрле үсеше өчен һәрьяклап файдалану максатларында, Россия Федерациясе Конституциясенең 73 һәм 76 статьялары, Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 статьясы нигезендә гамәлгә куела.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасына Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәүне туктаткан зат билгеләнеп куела.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнеп куела.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе үз вазыйфасыннан шәхси гаризасы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан азат ителә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына карамый.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе үз эшчәнлеген түләүсез нигездә гамәлгә ашыра.

**2 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, әлеге Законга, Татарстан Республикасының башка законнарына, шулай ук Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, шартнамәләренә һәм килешүләренә, халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына таяна.

**3 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең төп бурычлары**

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына аларның вәкаләтләрен нәтиҗәле гамәлгә ашыруда ярдәм итү;

гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары системасын үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

милли әдәбиятны, телне үстерүдә, татарларның үзенчәлеген саклап калуда ярдәм итү, шул исәптән Татарстан Республикасыннан читтә яшәүчеләренекен дә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләренең дә;

федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм аның Президиумының мөрәҗәгате буенча аерым миссияләрне үтәү.

4 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең төп хокуклары һәм вазыйфалары**

1. Үзенең төп бурычларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе:

1) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына тоткарлыксыз керә, аларның коллегиаль органнары эшендә катнаша, шулай ук, оештыру-хокукый рәвешенә һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга тоткарлыксыз керә;

2) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, вазыйфаи затлардан тиешле тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләү өчен кирәкле белешмәләр, документлар һәм материаллар соратып ала;

3) дәүләт органнарын һәм фәнни учреждениеләрне кирәкле эксперт тикшеренүләрен уздыруга һәм тиешле тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләүгә җәлеп итә;

4) Татарстан Республикасының дәүләт сәясәте, социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм идарә итүнең башка мәсьәләләре буенча дәүләт органнарына, вазыйфаи затларга үз тәкъдимнәрен һәм бәяләмәләрен җибәрә;

5) федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр, коммерциягә карамаган башка оешмалар белән бүтән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе җибәргән тәкъдимнәрне һәм бәяләмәләрне республика хакимият органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан карау мәҗбүри.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Татарстан Республикасы Президенты уздыра торган утырышларда, киңәшмәләрдә һәм башка чараларда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшендә, шулай ук алар уздыра торган киңәшмәләрдә һәм чараларда катнашырга, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясарга хокуклы.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Татарстан Республикасы Иминлек Советының, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелә торган башка органнарның составларына керергә, делегацияләрне җитәкләргә яисә аларның составларына

керергә, шулай ук федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары, чит дәүләтләрнең субъектлары һәм административ-территориаль берәмлекләре, халыкара оешмалар белән рәсми сөйләшүләр алып барганда катнашырга мөмкин.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе үз бурычларын гамәлгә ашыру максатларында фондларның, коммерциягә карамаган башка оешмаларның эшчәнлегендә законнарда һәм күрсәтелгән оешмаларның гамәлгә кую документларында билгеләнгән тәртиптә катнашырга хокуклы.

6. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенә аның бурычларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле соратып алына торган материалларны һәм документларны, башка мәгълүматны, әгәр үтенечнамәдә (мөрәҗәгатьтә) башка срок билгеләнмәгән булса, законнарда билгеләнгән срокларда җибәрергә тиеш.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе законнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән башка актлар, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары тарафыннан рәсми таратыла торган мәгълүмати һәм белешмә материаллар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин ителә.

### 5 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең закон чыгару эшчәнлегендә катнашуы**

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

### 6 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең эшчәнлеген тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына керә торган үз секретариаты була.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең эшчәнлеген тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратын тотуга каралган чыгымнар чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең даими урнашкан урыны һәм рәсми статусы**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең даими урнашкан урыны – Казан шәһәре, Кремль.

2. Татарстан Республикасында рәсми чаралар уздырылганда, шулай ук республикадагы башка чараларда катнашканда Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе рәсми дәрәҗә нигезендә Татарстан Республикасы Президентыннан соңгы урынны били.

8 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон, Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясына үзгәрешләр кертү белән бер үк вакытта үз көченә керә торган 5 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тота торган Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 30 марты
№ 11-ТРЗ